СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«САРАБИКУЛОВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
«САРАБИККОЛ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 17 марты № 4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге Советының 2013 елның 23 декабрендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм тезелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 6 декабрендәге 408-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Сарабиккол авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарабиккол авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге Советының 2013 елның 23 декабрендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1 статьяны** түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«блокланган төзелеш йорты - башка торак йорт (башка торак йортлар) белән бер рәттә гомуми ян стенасы (гомуми як стеналары) белән блокланган һәм җир кишәрлегенә аерым чыгу урыны булган торак йорт.»;

**22 статьяның 2 өлешенең 6 абзацын** «,шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 11 елешендә күрсәтелгән очракта;» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Сарабиккол авылы Киров урамы 4А,йортта - хакимият бинасында, Киров урамы 3А - гомуми белем бирү мәктәбе бинасында, Пионер урамы 45 йорт - «Сатурн - Урал» ҖЧҖ адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Сарабиккол авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Г.Р.Гаделшина